| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2023 г. Казань № 575-76/тэ-2023

Зеленодольск муниципаль районы «Радужный-2» торак комплексында «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2024 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.12.2023 № 57-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Зеленодольск муниципаль районы «Радужный-2» торак комплексында «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «РСК» ҖЧҖ) тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә әлеге карарның кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2023 № 575-76/э-2023
карарына кушымта

## Зеленодольск муниципаль районы «Радужный-2» торак комплексында «РСК» ҖЧҖ тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2024 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Тариф төре | Ел | Җылылык чыганагының төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | Пар |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | |
| | «Радужный-2» торак комплексында «РСК» ҖЧҖ | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | |
| | | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 664,45 | - |
| | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 787,59 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге